**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, республика дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген халык бәяләве йомгакларын карап тикшерү һәм анализлау буенча эксперт комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары, республика дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге турында, мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен һәм мәгълүмат технологияләрен кулланып, халыктан сораштырулар оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау хакында» 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-79 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 15 февралендәге ПУ-166 номерлы, 2014 елның 20 декабрендәге ПУ-1161 номерлы, 2015 елның 28 маендагы ПУ-497 номерлы, 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1226 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-458 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2020 елның 31 гыйнварындагы ПУ-55 номерлы, 2021 елның 13 мартындагы ПУ-234 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 16 сентябрендәге 717 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы шәһәр округлары һәм муниципаль районнары халкына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, республика дәрәҗәсендә һәм муниципаль дәрәҗәдә эш итүче унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр, акцияләренең контроль пакеты Татарстан Республикасы милкендә яки

муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләре җитәкчеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген халык бәяләве йомгакларын карап тикшерү һәм анализлау буенча эксперт комиссиясе (алга таба – эксперт комиссиясе) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) эксперт комиссиясе составыннан З.Р. Вәлиеваны, А.С. Груничевны, А.Р. Кадыйровны, А.Р. Хәйруллинны чыгарырга;

б) эксперт комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә:

Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын;

Насыртдинов Олег Рәшит улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт милке белән эш итү идарәсе башлыгын;

Начвин Илья Сергеевичны – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрын;

Терентьев Александр Михайловичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

в) эксперт комиссиясе әгъзасы Р.В. Гайнетдиновның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 06 июль
№ 546